| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ ХОЗЕСАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17 февраль 2023ел. Хуҗа Хәсән ав. № 12

«Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 11 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга һәм күрсәтелгән субсидияләрне һәм субсидияләрне федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетларына 2022 елда бирү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 05 апрелендәге 590 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм өч һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма коиттетының 2021 елның 11 октябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Субсидия алучы буларак баш бүлүчене бюджет акчаларын алучы буларак Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитетын тикшерү турындагы таләп субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары, шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Контроль-хисап палатасы (алга таба - КСП) тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү турында».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм https://hozesan-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Хуҗа Хәсән авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе С.П. Матвеева